БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

# ДУСЛЫК

КПССның ОКТЯБРЬ РАЙКОМЫ ҺӘМ ХАЛЫК ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ РАЙОН СОВЕТЫ ОРГАНЫ

ОРГАН ОКТЯБРЬСКОГО РАЙКОМА КПСС И РАЙОННОГО СОВЕТА НАРОДНЫХ ДЕПУТАТОВ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | №15 (7032) | 6 февраль, 1990 ел. СИШӘМБЕ | Бәясе 3 тиен.

**Кичә Мәскәүдә КПСС Үзәк Комитеты Пленумы үзенең эшен башлады**

## Кандидатлар белән очрашу

2 февральдә Биккол авылы клубында 868 нче Чирмешән территориаль сайлау округыннан РСФСР Верховный Советына депутатлыкка кандидат итеп күрсәтелгән мөгезле эре терлек симертү хуҗалыкара берләшмәсе шоферы М. М. Мусин, 38 нче Биккол сайлау округыннан Октябрь район Советына депутатлыкка кандидат итеп күрсәтелгән халык контроленың район комитеты председателе Ф. М. Галимов белән очрашу булды.

Очрашуның башында РСФСР Верховный Советына депутатлыкка кандидат М. М. Мусинның ышанычлысы Югары Норлат мәктәбе укытучысы Т. Г. Гыймадиев аның тормыш һәм хезмәт юлы белән таныштырды. Кандидатның икенче ышанычлысы «Агропромхимия» берләшмәсе экономисты М. И. Сираев сайлаулар көнне тавышны аңа бирергә чакырды. Аннан соң Миндамир Мәхмүтович Мусин авыл халкын үзенең платформасының төп положениеләре белән таныштырды.

Ф. М. Галимовның ышанычлысы буларак, «Таң» колхозы парткомы секретаре Н. Мифтахов аның турында җылы сүзләр әйтте. Фатыйх Миннеханович шул авылда туып үскән кеше, аның тормыш һәм хезмәт юлы да халык күз алдында. Ул залдагыларга киләчәктә төзеләчәк объектлары, яңартылачак биналары белән авылның макетын күрсәтте.

Депутатлыкка кандидатларның икесен дә хуплап «Таң» колхозы председателе Ә. Н. Рәхмәтуллин чыгыш ясады. Пенсионерлар Р. Нуруллина, Н. Вәлиәхмәтова, һәм, гомумән, залдагылар кандидатларга зур ышаныч белдерделәр.

**Ф. ВӘГЫЙЗОВА.**

Тикшерүченең эше катлаулы һәм күпкырлы. Ул хезмәткәрләргә барлык җинаять-процессуаль законнарны белүне генә түгел, кешеләрнең башкалар язмышына мөнәсәбәте кебек катлаулы ситуацияләрне белү дә мөһим. Район эчке эшләр бүлеге тикшерүчесе, милициянең өлкән лейтенанты Х. С. Зартынов нәкъ әнә шушы сыйфатларга ия дә.

Хәлил Сәрвәретдинович бу хезмәттә әле яңа кеше. Ләкин ул берничә катлаулы җинаять эшен тикшерергә өлгерде инде һәм үзенең әлеге профессияне сайлап ялгышмавын күрсәтте.



Рәсемдә: район эчке эшләр бүлеге тикшерүчесе, милициянең өлкән лейтенанты Х. Зартынов.

## Яуланган чик түгел

**Муса Җәлил исемендәге колхоз.** Кәкре Атау бригадасындагы сөтчелек комплексында эшләүче терлекчеләрнең олысыкечесе үзләренең социалистик йөкләмәләрен үтәп чыгу өчен фидакарь хезмәт куя. 15 елдан артык шул тармакта эшләүче Зәйнелгарәп Гыйләҗева үз кулыннан лидерлыкны ычкындырмый. Үткән елда үз карамагындагы малларның һәрберсеннән 4002 килограмм сөт савып алды ул. Аның белән бергә эшләүче Тәслимә Рәхимова, Миннегөл Сафиуллина, Нурзидә Алиева үз группаларындагы терлекләрдән 3590—3500 килограмм продукция алдылар. Әлбәттә, бу уңышка уңган терлекчеләр намуслы хезмәт куеп ирештеләр.

Бикүле товарлыклы-сөтчелек фермасыннан Гөлсирә Габитова да мул продукция җитештерү өчен зур тырышлык куя.

Шунысын да әйтергә кирәк, бу савучыларның хезмәт уңышында җәйге айларда көтү көткән, кышлату чорында малларга азык кайтаручы һәм башка вак-төяк эшләрне башкаручы комсомолецлар Илһам Хәсәнҗанов, Фәһим Сафин һәм өлкән терлекче Мансур Якуповларның да өлеше бар.

**Г. САДЫЙКОВА.**

## Зур тырышлык куеп

**«Тәрнәс» совхозы.** Товарлыклы-дуңгызчылык фермасы коллективы еллык планнарны һәм кабул итеп алынган социалистик йөкләмәләрен үтәү өчен зур тырышлык куеп һәм фидакарьлек үрнәге күрсәтеп эшли.

Январь аенда Владимир Кузьмин җитәкчелегендәге звено дуңгызлардан 373 грамм уртача тәүлеклек артым алуга ирешсә, Николай Пронин группасында ул 379 грамм тәшкил итте.

**Т. ВАРЛАМОВА,**
баш экономист.



## Хезмәтенә күрә җимеше

**Синдряков исемендәге колхоз.** Беренче товарлыклы-сөтчелек фермасыннан мөгезле эре терлек симертүче арендачылар Рифкать Хәлиуллин һәм Нина Прагашкина алты айга кадәр булган бозаулардан аеруча әйбәт артым алуга ирешәләр. Мәсәлән, январь аенда аларның уртача тәүлеклек артымнары 885 грамм тәшкил итте.

Икенче товарлыклы-дуңгызчылык фермасы арендачылары Зоя Яковлева, Венера Макарова һәм Лидия Маркованың куйган хезмәтләренә дә сокланырлык. Алар январь аенда дуңгызлардан 420—442 граммга кадәр артым алуга ирештеләр. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, Венера Макарова пенсия яшендә булса да, элеккечә үзенең хезмәт урынында.

Хуҗалыкның беренче товарлыклы-дуңгызчылык фермасында да мактаулы арендачылар бар. Яңа гына аренда подрядында эшли башлаган Александр Сидоров, Анатолий Николаев шундыйлардан. Аз гына вакыт узуга да карамастан, алар үзләре карамагындагы дуңгызлардан 448 грамм уртача тәүлеклек үсеш алдылар.

Сергей Чугунов җитәкчелегендәге беренче һәм Алексей Васильев җитәкчелегендәге икенче товарлыклы-дуңгызчылык фермалары буенча январь аенда дуңгызларның уртача тәүлеклек үсешләре 403—406 шар грамм тәшкил итте.

**Н. КУЗНЕЦОВА,**
баш экономист.

## Алтын куллы осталар

«Татнефтестрой»ның 53 нче төзү-монтаж идарәсе коллективы узган елгы планнарны уңышлы үтәде.

Агымдагы елның январь аенда да Владимир Петрович Сухов һәм Николай Иванович Сухарев җитәкчелегендәге ташчылар бригадалары 240 мең сум урынына 240,1 мең сумлык эш башкардылар. Мондый күркәм нәтиҗәләргә ирешүдә ташчылардан Николай Белов, Евгений Крайнов, Сәгыйть Вәлитов, Вахит Ильмухин, Вячеслав Тахтаманов, Николай Краснов үзләреннән аеруча зур өлеш керттеләр. Слесарь-монтажчылар бригадасы да нефть үткәргечләр сузуда өлгерлек күрсәттеләр. Алар эшне яхшы сыйфатлы итеп башкардылар.

Штукатур-буяучылардан исә Мария Никитовна Маликова һәм Сәлимә Солтангалиевна Сабирова җитәкчелегендәге бригадаларга тиңнәр табылмады. С. Сабирова бригадасы 75 квартиралы йортны срогыннан алда файдалануга тапшырды. Ә М. Маликова бригадасы планда каралган 60 квартиралы йортны үзвакытында өлгертүгә иреште. Биредә Надежда Литвин, Людмила Меркулова, Миннегөл Мөхәммәтова, Мәдинә Сәйфетдинова, Валентина Патюк, Зәрия Әхмәтсафина кебек осталарның уңганлыгын һәм тырышлыгын искә алырга кирәк.

**А. ЕВЛЕНТЬЕВА,**
хезмәткә түләү бүлеге буенча өлкән инженер.

## Газета укучылар игътибарына!

**Тиешле югары оешмаларның редакцияне кәгазь белән тәэмин итмәүләре сәбәпле, «Дуслык» газетасының киләсе саннарын чыгаруда өзеклекләр булырга мөмкин.**

**АДМИНИСТРАЦИЯ.**

## Алдынгылар

Механизаторлар отрядында озак еллар тракторчы булып эшләүче Әнвәр Идрисовка «корыч айгыр»ларның төрлесен иярләргә туры килде. Соңгы вакытта ул көпчәкле ЮМЗ-6 тракторын йөртә. Аның белән хуҗалык эчендә төрле наряд үти. Терлек азыгы хәзерләү, салам җыю кебек мөһим кампанияләрдән дә читтә калмый. Җәмәгать малларына азык та кайтара. Район үзәгеннән төзелеш материаллары һәм минераль ашламалар да ташый. Бер сүз белән әйткәндә, ел әйләнәсе бертуктаусыз җиткерелгән нарядны үти. Карусыз фидакарь хезмәт куеп, механизаторлар арасында җәелдерелгән социалистик ярышта призлы урыннарны яулый. Үткән елда да күркәм нәтиҗәләргә иреште ул. Үзенә җиткерелгән планны 192 процентка үтәде. МТЗ-80 тракторын йөртүче Владимир Ермолаев та планны 141 процентка үти алды. Чылбырлы тракторлар йөртүчеләр арасында ДТ-75 тракторын ияpләүче Геннадий Менделеевка тиңнәр юк.

Автомобиль йөртүчеләр арасында ГАЗ-53 автомашинасын идарә итүче Владимир Ишкальдин беренчелекне яулады. Ул иң күп тонна-километрда эш башкарды. КамАЗ-5320 шоферы Валерий Пчеляков планны 161 процентка үтәп, икенче булды. ГАЗ-53 машинасын йөртүче комсомолец Андрей Тумаков өченче урынга лаек булды.

**М. САФИН,**
«Знамя Октября» колхозы.

# 1990 елның 4 марты—халык депутатларын сайлаулар көне

## 868 нче Чирмешән территориаль сайлау округы буенча РСФСР халык депутатлыгына кандидат



## МИНДАМИР МӘХМҮТОВИЧ МУСИН

Миндамир Мәхмүтович Мусин 1954 елда Татарстан АССРның Октябрь районы Югары Норлат авылында туа. Милләте буенча татар, 1982 елдан КПСС члены.

Ул хезмәт эшчәнлеген 1971 елда Октябрь районы Хафизов исемендәге колхозда колхозчы булып башлый. 1972—1974 елларда Совет Армиясе сафларында хәрби хезмәт срогы уза. 1975 елда Миндамир Мәхмүтович Лениногорск шәһәрендә автомәктәп тәмамлый.

Шул елдан алып ул бүгенге көнгә кадәр туган авылында яши, берләшмәдә шофер булып эшли. Ул эшләгән коллектив хәзер аренда подрядына күчте.

Миндамир Мәхмүтович производствоны камилләштерү буенча рационализаторлык тәкъдимнәре кертә, яшьләр өчен остаз булып тора. 1984 елдан бирле ул «Районның алдынгы шоферы» исемен ел саен раслап килә.

М. М. Мусин КПССның Октябрь райкомы члены, хуҗалыкара берләшмәнең механизация цехында партия группасы җитәкчесе. Хезмәттәге уңышлары күп тапкырлар Почет грамоталары һәм дипломнар белән билгеләп узылды.

Миндамир Мәхмүтович экономик белем мәктәбендә үзенең идея-политик һәм профессиональ белемен күтәрә. Анда өйрәнелә торган мәсьәләләрне тикшерүдә актив катнаша, принципиаль фикер белдерә.

КПССның Октябрь райкомы пленумы Миндамир Мәхмүтович Мусинны 868 нче номерлы Чирмешән территориаль сайлау округы буенча РСФСР халык депутатлыгына кандидат итеп күрсәтте.

## М. М. Мусинның сайлау алды платформасының төп положениеләре

Мин үземнең сайлау алды платформамны авыл хуҗалыгы өлкәсендә еллар буе җыелып килгән проблемаларны исәпкә алып төзедем. Колхозларның һәм совхозларның ярлылана баруын, авыл халкының кимүен туктату зарури. Ярлы авыл шәһәрне туендыра алмый дип саныйм. Без, авылда яшәүчеләр, шәһәр халкы алдында зур бурычлы икәнлегебезне тирәнтен аңлыйбыз. Азык-төлек кибетләре киштәләренең ярлылыгы, күп төрле продуктларның җитешмәве өчен шәһәрдә яшәүчеләр безгә белдергән нигезле дәгъвалар безне дә дулкынландыра.

Әмма авыл да, үз чиратында, ярдәмгә мохтаҗ әле. Азык-төлек белән тәэмин итү мәсьәләсен гамәлгә ашыру өчен авылга мөнәсәбәтне үзгәртергә: социаль-көнкүреш шартларын яхшыртырга, уңайлылыклар тудырылган тораклар, юллар, больницалар, медицина пунктлары, мәктәпләр, балалар бакчалары, сәүдә предприятиеләре, көнкүреш службалары төзергә, аның социаль йөзен шәһәрнеке дәрәҗәсенә җиткерергә кирәк. Бары шул вакытта гына халыкның авылдан китүен туктатырга һәм Азык-төлек программасын хәл итәргә мөмкин.

Бүген авыл үзгәреш чоры кичерә. Безнең барлык хаталарыбызның нәтиҗәсе буларак, крестьян җирдән читләште. Төп бурыч булып аны тулы хокуклы хуҗага әверелдерү кирәк. Шуңа күрә авылның тормыш дәрәҗәсен яхшырту мәсьәләсен хәл итүгә бәйле чараларны үземнең гражданлык бурычым итеп саныйм, бары шул чагында гына аның илне туйдыручы булачагына ышанам. Моңа аренда һәм гаилә подряды аркылы ирешү мөмкин дип саныйм. Колхозчыларга озак срокка җирне арендага тапшыру, җир турында закон кабул итүне тизләтү кирәк, бу аларга тулы мөстәкыйльлек һәм хокук ягыннан гарантия китерәчәк. Социалистик авыл хуҗалыгының нигезен тәшкил иткән колхозлар һәм совхозларның мөмкинлекләрен дә тулы ачу мөһим.

Колхозларны һәм совхозларны материаль тәэмин итү системасын камилләштерүне яклыйм. Социаль бурычлардан «Торак» программасын гамәлгә ашыруны беренче чираттагы бурыч итеп саныйм. Аны чынбарлыкка әверелдерү өчен вакытлыча промышленность төзелешен туктатып торуны максатка ярашлы булыр иде дип уйлыйм.

Саф һава, чиста чишмә, елгалар, күлләр кеше сәламәтлегенә дә уңай йогынты ясый, шуның өчен экологик экспертиза үткәрмичә торып төрле объектлар коруны законсыз саныйм.

Миңа авылда яшәүче өлкән буын кешеләренең кыенлыклары аңлашыла. Аларның йортларын тәртиптә тоту, кышкы чорга ягулык, мал азыгы туплау, автобуслар хәрәкәтен җайга салу мәсьәләләрендә, әгәр депутат булып сайлансам, хәлдән килгәнчә ярдәм итәргә тырышырга сүз бирәм. Авылларга газ кертү, юллар төзүне тизләтү өчен бар тырышлыгымны куячакмын. Яшьләргә аерым игътибар бирү кирәк. Аларны торак һәм эш белән тәэмин итү, һәрьяклы үсешләре өчен мөмкинлекләр тудыру игътибар үзәгендә торыр. Бер үк вакытта тиешенчә социаль тәэмин ителмәгән категория хезмәт ияләре: күп балалы гаиләләр, ятимнәр, инвалидлар интересын яклап чыгам. Хатын-кызларның тормыш хәлен җиңеләйтү, аларның ана һәм хатын буларак хокукларын һәм вазифаларын яклауны мөһим бурыч итеп күрәм.

Законнар кабул иткәндә хезмәт кешесе хокукларын тулы тәэмин итүләрен яклап тавыш бирәчәкмен. Илебез халыклары арасында реаль тигезлекне тәэмин итүне гаять мөһим саныйм.

Барлык бу чараларны җәмәгатьчелек, округ сайлаучыларының актив ярдәме белән тормышка ашыру өчен тырышырмын. Депутат буларак, үз бурычымны мине тәкъдим иткән сайлаучыларның интересларын яклауда күрәм. Республика властеның югары органында сайлаучыларның лаеклы вәкиле булу өчен бар тырышлыгымны куячакмын.

## Яңача эшлибез

Яңа уку елы башыннан ук Егоркино урта мәктәбенең Н. П. Михеев исемендәге дружина советы үзенең эшен үзгәртеп корырга карар кылды. Беренче сборда ук пионер отрядлары класс сәгатьләре урынына коллектив белән иҗат эшләре оештыру яхшырак булыр дип таптылар.

Ә бу эш нәрсәсе белән кызыксындыра соң укучыларны?

Һәр эш тәрбия бурычларын тормышка ашыруда бик әйбәт мөмкинлек ача. Яңа эшне пионерлар вожатый, укытучылар, коллектив белән бергә планлаштыралар, хәзерлиләр, үткәрәләр, тикшерәләр. Алар эшнең һәр этабында алда торган бурычларны хәл итүдә яңа юллар, вариантларны бергәләп эзлиләр.

Эшлекле уен формасында мәктәптә бал уздыруны планлаштырдык. Хәер, мондый чараларны элек тә үткәрә идек. Әмма монысы барлык пионерларның да актив катнашы белән барды. Аннан соң «Ел дәвамы» дигән коллектив туган көнне билгеләп үттек. Ул укучыларга аеруча ошады.

Коллектив белән иҗат эшләре үткәрү балаларны бер-берсенә якынайта. Чыннан да, пионерлар үзара дустанә яши башладылар, отрядлар арасында элемтә ныгыды. Пионерлар кабул ителгән бурычларны мөстәкыйль тормышка ашыралар, отряд, мәктәп коллективында да билгеле яңалыклар, уңай хәлләр тудыралар. Яңа чара уздырылганнан соң эшкә йомгак ясыйлар.

Хәзер балалар «Нәрсә? Кайда? Кайчан?» турнирына хәзерләнәләр.

**Г. ТЕРЕНТЬЕВА,**
Егоркино урта мәктәбенең өлкән пионервожатые.



Комсомолец егет Вадим Васильевны сөт-май заводында яхшы beләләр. Намуслы, тырыш хезмәте белән күпләргә үрнәк булып тора ул. Вадим слесарь-ремонтчы хезмәтен башкара. Алар бригада подрядында эшлиләр. Кулы эшкә ятып торган егет кайда четреклек килеп чыга, җитешсезлекләр туа — шунда ук килеп җитә һәм эшне җайга сала. Ул үзе сөт промышленносте буенча Димитровград шәһәрендәге механика-технология техникумын тәмамлады. Шунлыктан биредәге техниканы да биш бармагы кебек яхшы белә. Ул башлангыч комсомол оешмасы секретаре да. Спорт белән даими шөгыльләнә. Аеруча футболны ярата. Үзе дә команда данын яклап уйный.

Рәсемдә: слесарь-ремонтчы В. К. Васильев.

Л. Шәмсуаров фотосы.

